| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН СОВЕТ<br>АКСУНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>АКСУ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

24 май 2021 ел　　　　　　　　　　　　　　　№ 21-2

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект карары хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Граждан кодексы, «СанПиН 2.1.7.3550-19 санитар-эпидемиологик кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында «Муниципаль берәмлекләр территорияләрен тотуга санитар-эпидемиологик таләпләр һәм нормалар раслау турында» Россия Федерациясенең 2019 елның 05 декабрендәге 20 номерлы баш дәүләт санитария табибының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 14 ноябрендәге 40-3 номерлы карары белән расланган (14.07.2018 № 54-3, от 09.09.2019 № 73-1, от 05.08.2020 № 92-1, от 24.12.2020 № 9-1 карарлары редакциясендә), Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә (алга таба - Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

93 пунктны үзгәртергә һәм киләсе редакциядә бәян итәргә:

«93. Стационар булмаган объектларны урнаштыру мондый объектларны муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә урнаштыру схемасы буенча, хокук иясенең стационар булмаган объектка хокук билгели торган документлары булганда гамәлгә ашырыла.

Тиешле тәртиптә оешкан һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләре милекчеләре өчен, әгәр бу Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса, аларда стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында карар кабул итү мөмкинлеге кире кагылмый..»;

156.13 пунктын төшереп калдырырга;

156.14.-156.17 пунктлар нумераиясен 156.13.-156.16. нумераиясе дип санарга

2. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын расларга.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

-эшче төркем җитәкчесе:

Хәйретдинов Марат Мөнир улы– Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы,

-эшче төркем әгъзалары:

Шәрәфуллина Гөлназ Илдус кызы – Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре (килешү буенча);

Сибгәтуллин Әнсар Мансур улы – Буа муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе (килешү буенча);

Валеева Резедә Нәгыйм кызы – Буа муниципаль районы Советы Аппаратының авыл җирлекләре белән эшләү бүлеге башлыгы (килешү буенча),

Усманова Айгөл Марат кызы – Буа муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге баш белгече (килешү буенча).

3. Билгеләргә:

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422415, ТР, Буа районы, Аксу авылы, Үзәк ур., 116а нчы йорт, язма рәвештә, карар проекты рәсми басылып чыккан көннән алып 30 көн эчендә, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларда яки ачык тыңлауларда катнашып, чыгыш ясау хокукы өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча тапшырыла: 422415, ТР, Буа районы, Аксу авылы, Үзәк ур., 116а нчы йорт, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, ачык тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча.

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләнгән тәртиптә, 2021 елда “15” июньгә 11.00 сәгатьтә Аксу авыл мәдәният йорты бинасында: 422415, ТР, Буа районы, Аксу авылы, Үзәк ур., 116а нче йорт адресы буенча билгеләргә.

4. Эшче төркемгә «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карар проектына тәкъдимнәрне өйрәнергә һәм гомумиләштерергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Буа муниципаль районы Аксу<br>авыл җирлеге башлыгы М.М. Хәйретдинов